ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ПРИВОЛЖСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

№ 119

«20» ноябрь 2024 ел

«Туристлык салымы турында»

Россия Федерациясе Салым кодексының 33.1 бүлеге нигезендә, «Приволжский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Приволжский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карар кабул итте:

1. 2025 елның 01 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Приволжский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә туристлык салымын билгеләргә.

2. Салым ставкаларын түбәндәге күләмнәрдә билгеләргә: 2025 елда – 1 процент, 2026 елда – 2 процент, 2027 елда – 3 процент, 2028 елда - 4 процент, 2029 елдан башлап-5 процент.

3. Салым түләү тәртибен Россия Федерациясе Салым кодексының 418.8 статьясы нигезендә билгеләргә.

4. Вакытлыча яшәү буенча хезмәт күрсәтүләрнең бәясе салым базасына кертелми торган физик затлар категорияләре Россия Федерациясе Салым кодексының 418.4 статьясының 2 пункты белән билгеләнгән.

5. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Приволжский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә туристлык салымын исәпләү тәртибе Россия Федерациясе Салым кодексының 418.7 статьясы нигезендә билгеләнә.

Россия Федерациясе Салым кодексының 418.7 статьясы нигезендә исәпләнгән туристлык салымы суммасы 100 сумның тапкырлавы һәм яшәү тәүлеге саны буларак исәпләнгән минималь туристлык салымы суммасыннан кимрәк булган очракта, туристлык салымы суммасы минималь туристлык салымы күләмендә билгеләнә.

6. Әлеге карарның 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керүен билгеләргә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының рәсми сайтында http://spasskiy.tatarstan.ru, Приволжский һәм Ржавец торак пунктларындагы мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Приволжский авыл җирлеге башлыгы — С.Г.Спирин

СОВЕТ ПРИВОЛЖСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ